КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 22 апрель г.Казань № 256

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының яшьләр сәясәте буенча дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 14 август, 665 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының яшьләр сәясәте буенча дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 14 август, 665 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 21 июнь, 505 нче, 2020 ел, 31 гыйнвар, 54 нче, 2021 ел, 26 июль, 645 нче, 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы, 2022 ел, 9 февраль, 102 нче, 2022 ел, 1 апрель, 304 нче, 2022 ел, 20 июнь, 587 нче, 2022 ел, 14 сентябрь, 1002 нче, 2023 ел, 21 февраль, 171 нче, 2023 ел, 16 октябрь, 1312 нче, 2024 ел, 18 июнь, 434 нче, 2024 ел, 13 сентябрь, 785 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы ведомство буйсынуындагы яшьләр сәясәте буенча дәүләт оешмалары һәм кайбер бертип булмаган оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Яшьләр сәясәте оешмаларында хезмәткәрләрнең база окладларын билгеләү

2.1. Яшьләр сәясәте оешмаларында физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | 1 айга база окладың күләме, сум |
|---|---|---|
| Икенче дәрәҗә физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалифи-кация дәрәҗәсе | Хореограф | 24 190 |

2.2. Яшьләр сәясәте оешмаларында мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | 1 айга база окладың күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Беренче дәрәҗә уку-укыту буенча ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Уку-укыту эшләре бүлеге секретаре | 23 600 |
| Икенче дәрәҗә уку-укыту буенча ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Режим буенча кизү торучы | 23 720 |
| | Кече тәрбияче | |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Хезмәт буенча инструктор | 24 900 |
| | Физик культура буенча инструктор | |
| | Музыка җитәкчесе | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Концертмейстер | 25 000 |
| | Өстәмә белем бирү педагогы | |
| | Оештыручы педагог | |
| | Социаль педагог | |
| | Мөгаллим тренер | |
| | Инструктор-методист | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | 25 140 |
| | Өлкән инструктор-методист | |
| | Тәрбияче | |
| | Өлкән мөгаллим тренер | |
| | Педагог-психолог | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | 25 250 |
| | Укытучы-логопед (логопед) | |
| | Өлкән тәрбияче | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлекчә: кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту һәм консультация бирү пункты, укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе һәм балаларга өстәмә белем бирә торган мәгариф программалары тормышка ашырылган башка структур бүлекчәләр мөдире | 25 300 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Мәгариф программасы һәм балаларга өстәмә белем бирә торган мәгариф программасы тормышка ашырылган, аерымланган структур бүлекчә мөдире (башлыгы) | 25 350 |

«Яшьләр белән эшләү буенча белгеч» һәм «яшьләр белән социаль эшләү буенча белгеч» вазыйфаларын биләгән хезмәткәрләрнең база оклады 25 000 сум тәшкил итә.

2.3. Яшьләр сәясәте оешмаларында медицина хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Диета шәфкать туташы (диета медицина браты) | 24 740 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы (медицина абыйсы) | 25 240 |
| | Массаж буенча шәфкать туташы (массаж буенча медицина абыйсы) | |
| «Табиблар һәм провизорлар» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән башка) | 29 170 |

Яшьләр сәясәте оешмаларында медицина хезмәткәрләре өчен база окладына карата тармак өстенлеге коэффициенты кулланыла. Тармак өстенлеге коэффициенты күләме 1,1 тәшкил итә.

База окладына карата әлеге коэффициентны куллану яңа база оклады барлыкка китерә һәм ул компенсация һәм стимул бирү характерындагы түләүләрне исәпләгәндә исәпкә алына.

2.4. Яшьләр сәясәте оешмаларында мәдәният хезмәткәрләре вазыйфаларының база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|
| 1 | 2 |
| «Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Билетлар контролеры | 24 450 |
| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Аккомпаниатор | 24 950 |
| Костюмнар бүлеге мөдире | |
| Мәдәни чаралар оештыручы | |
| Түгәрәк, һәвәскәр берләшмә, кызыксынулар буенча клуб җитәкчесе | |
| «Төп звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Аккомпаниатор-концертмейстер | 25 450 |
| Тавыш операторы | |
| Кинооператор | |
| Китапханә, музей һәм башка шундый учреждениеләр һәм оешмалар мөхәррире | |
| Клуб эше методикасы буенча белгеч | |
| Яктылык буенча рәссам | |
| Рәссам-декоратор | |
| Бизәүче рәссам | |
| Рәссам-фотограф | |
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Мәдәният йорты (сарае) бүлеге (секторы), мәдәният һәм ял паркы, халык иҗатының фәнни-методик үзәге, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияте (мәдәният һәм ял итү) үзәге һәм башка шундый учреждениеләр һәм оешмалар мөдире | 26 650 |
| Тавыш режиссеры | |
| Куючы режиссер | |
| Режиссер (дирижер, балетмейстер, хормейстер) | |
| Массакүләм тамашалар режиссеры | |

| 1 | 2 |
|---|---|
| Сәнгать җитәкчесе | |

Яшьләр сәясәте оешмаларында мәдәният хезмәткәрләре өчен база окладына карата тармак өстенлеге коэффициенты кулланыла.

Тармак өстенлеге коэффициентының күләме түбәндәгечә тәшкил итә:

«Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме буенча – 1,05;

«Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һәм «Төп звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркемнәре буенча – 1,12;

«Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазифалары» һөнәри квалификация төркеме буенча – 1,25;

База окладына карата әлеге коэффициентларны куллану яңа база окладыбарлыкка китерә һәм ул компенсация һәм стимул бирү характерындагы түләүләрне исәплəгәндә исәпкә алына.

«Созвездие – Йолдызлык» иҗади сәләтле балаларга һәм яшьләргә ярдәм күрсәтү буенча республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең «Созвездие – Йолдызлык» арт-резиденциясе өчен:

«труппа мөдире», «вокал буенча репетитор», «балет артисты», «драма артисты», «симфоник, камера, эстрада-симфоник, тынлы оркестрлар, халык уен кораллары оркестры» вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрнең база окладры 25 000 сум тәшкил итә;

«баш дирижер», «баш режиссер», «әдәбият-драматургия өлеше җитәкчесе», «сәнгатьчә кую өлеше мөдире», «музыка өлеше мөдире» вазыйфасын биләүче хезмәткәрләрнең база оклады 33 310 сум тәшкил итә.»;

16 нчы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16 нчы таблица

Яшьләр сәясәте оешмалары җитәкчеләренең төп окладлары күләмнәре

| Т/с | Оешма тибының атамасы / оешманың штат саны, берәмлек | Хезмәт өчен түләү төркеме | Җитәкченең база окладыˣ, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Яшьләр үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр (10 ны кертеп) | 1 | 35 200 |
| | 11 дән 30 га кадәр (30 ны кертеп) | 2 | 39 270 |
| | 31 дән 50 гә кадәр (50 не кертеп) | 3 | 44 220 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | 51 дән 70 кә кадәр (70 не кертеп) | 4 | 47 190 |
| | 71 дән 150 гә кадәр (150 не кертеп) | 5 | 49 170 |
| | 151 дән | 6 | 55 220 |
| 2. | Сәламәтләндерү-ял итү учреждениеләре (лагерьлар) | | |
| | 10 га кадәр (10 ны кертеп) | 1 | 37 400 |
| | 11 дән | 2 | 40 150 |
| 3. | Яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клублары | | |
| | 12 гә кадәр (12 не кертеп) | 1 | 35 200 |
| | 13 тән 25 кә кадәр (25 не кертеп) | 2 | 40 150 |
| | 26 дан 40 ка кадәр (40 ны кертеп) | 3 | 45 210 |
| | 41 дән 70 кә кадәр (70 не кертеп) | 4 | 47 190 |
| | 71 дән 140 ка кадәр (140 ны кертеп) | 5 | 50 270 |
| | 141 дән | 6 | 73 150 |
| 4. | Хәрби-патриотик эшләр һәм хәрби хезмәткә чакырганга кадәр әзерләү үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр (10 ны кертеп) | 1 | 29 700 |
| | 11 дән 20 гә кадәр (20 не кертеп) | 2 | 38 940 |
| | 21 дан | 3 | 48 180 |
| 5. | Иҗтимагый тәртипне саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр (10 ны кертеп) | 1 | 36 850 |
| | 11 дән 30 га кадәр (30 ны кертеп) | 2 | 42 240 |
| | 31 дән 50 гә кадәр (50 не кертеп) | 3 | 43 340 |
| | 51 дән 70 кә кадәр (70 не кертеп) | 4 | 44 440 |
| | 71 дән 90 га кадәр (90 ны кертеп) | 5 | 45 540 |
| | 91 дән | 6 | 46 640 |
| 6. | Балалар һәм яшүсмерләр ялын, аларны савыктыруны һәм эш белән тәэмин итүне оештыру үзәкләре | | |
| | 45 кә кадәр (45 не кертеп) | 1 | 45 100 |
| | 46 дан 90 га кадәр (90 ны кертеп) | 2 | 49 500 |
| | 91 дан | 3 | 53 900 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 7. | Студентлар хезмәт отрядлары үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр (10 ны кертеп) | 1 | 43 120 |
| | 11 дән 30 га кадәр (30 ны кертеп) | 2 | 44 220 |
| | 31 дан | 3 | 45 320 |
| 8. | Балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр (10 ны кертеп) | 1 | 44 110 |
| | 11 дән 25 кә кадәр (25 ны кертеп) | 2 | 47 410 |
| | 26 дан | 3 | 50 710 |
| 9. | Балалар һәм яшьләр өчен телефоннан ашыгыч психологик ярдәм үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр (10 ны кертеп) | 1 | 42 900 |
| | 11 дән 30 га кадәр (30 ны кертеп) | 2 | 47 300 |
| | 31 дән 50 гә кадәр (50 не кертеп) | 3 | 51 700 |
| | 51 дән 70 кә кадәр (70 не кертеп) | 4 | 56 100 |
| | 71 дән | 5 | 61 600 |
| 10. | Девиант тәртипле балалар өчен социаль тернәкләндерү үзәге | | |
| | 20 га кадәр | 1 | 50 600 |
| | 20 дән 40 ка кадәр (40 ны кертеп) | 2 | 52 800 |
| | 41 дән 60 ка кадәр (60 ны кертеп) | 3 | 55 000 |
| | 61 дән | 4 | 57 200 |
| 11. | Яшьләргә ярдәм күрсәтү үзәкләре | | |
| | 12 гә кадәр (12 не кертеп) | 1 | 35 200 |
| | 13 тән 25 кә кадәр (25 не кертеп) | 2 | 40 150 |
| | 26 дан 40 ка кадәр (40 ны кертеп) | 3 | 45 210 |
| | 41 дән 70 кә кадәр (70 не кертеп) | 4 | 47 190 |
| | 71 дән 140 ка кадәр (140 ны кертеп) | 5 | 50 270 |
| | 141 дән | 6 | 73 150 |
| 12. | Яшьләр, инновация һәм профилактика программалары буенча республика үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр (10 ны кертеп) | 1 | 35 200 |
| | 11 дән 30 га кадәр (30 ны кертеп) | 2 | 39 270 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | 31 дән 50 гә кадәр (50 не кертеп) | 3 | 44 220 |
| | 51 дән 70 кә кадәр (70 не кертеп) | 4 | 47 190 |
| | 71 дән 150 гә кадәр (150 не кертеп) | 5 | 49 170 |
| | 151 дән | 6 | 55 220 |

____________________

*Яшьләр сәясәте буенча дәүләт оешмалары җитәкчеләре өчен башкарыла торган эшләрнең катлаулылыгын һәм мөһимлеген исәпкә алып, шулай ук яшьләр сәясәте буенча муниципаль оешмаларга эшчәнлек юнәлеше буенча оештыру ягыннан һәм методик ярдәм күрсәтүгә бәйле рәвештә, төп окладка карата арттыру коэффициенты 1,1 күләмендә билгеләнә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының яшьләр сәясәте буенча дәүләт оешмалары эшчеләр гомумтармак эшче һөнәрләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең II бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Яшьләр сәясәте оешмаларында эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү

2.1. Яшьләр сәясәте оешмаларында эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|
| «Беренче баскыч эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 23 320 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 23 520 |
| «Икенче дәрәҗә эшчеләр гомумтармак һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 23 660 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 23 840 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 24 020 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 24 550 |

2.2. Яшьләр сәясәте оешмаларында җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | 1 айга төп оклад күләме, сумтөп |
|---|---|
| 1 | 2 |
| «Беренче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 23 320 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 23 520 |
| «Икенче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 23 660 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 23 840 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 24 020 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 24 240 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 24 430 |
| «Өченче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 24 620 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 24 820 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 25 050 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 25 250 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 25 450 |
| «Дүртенче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 26 400 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 26 600 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 26 800». |

2. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин